РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Чалпинского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Центральная, д.35, с. Чалпы, 423324
Тел. (8-5592) 35-5-46, факс (8-5592) 35-5-46
Chal.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Чалпы авыл жирлеге
башкарма комитеты

Узэк урамы, 35, Чалпы авылы, 423324
Тел. (8-5592) 35-5-46, факс (8-5592)35-5-46
Chal.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» сентябрь 2019 ел №69

Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22, 56 статьялары, 24.03.2004 ел №23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, карар чыгарам:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

2018 елдагы, 2019 елнын 1 нче январь көненә калган үзара салым акча калдыкларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү: «Чалпы, Камышлы, Ирекле, Балан-Бүләк авылларында көнкүреш калдыкларын, чүп-чарны жыю, чыгару һәм үтилләштеру» юнәлешеннән Чалпы авылында Ленин урамына, Яшьләр урамына, Бакчалы урамына, Яңа урамына, Гагарин урамына, Казан урамына, Балан-Бүләк авылында Ленин урамына, Камышлы авылында Яшьләр урамына, Ирекле авылында Гагарин урамына, Наратлы урамына «Вак таш җәелгән юлларның чокырларын ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү) » кебек сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карар түбәндәге чаралар аша халыкка игълан ителергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Чалпы авылы, Ленина ур., 130 йорт, Үзәк ур., 39 йорт, Чалпы авылы мәктәп бинасында, амбулатория бинасында урнашкан мәгълүмат стендларында, Камышлы, Ирекле, Балан-Бүләк авыллары мәгълүмат стендларында;
- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,
- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Башлык: А.М.Мөхәммәтшин